РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛНЫЙ КОМИТЕТ МЕЛЛЯ-ТАМАКСКОГО**

**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ**

**РАЙОНЫ МӘЛЛӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

*Мәллә--Тамак авылы* “ 04 ” сентябрь 2025 ел

КАРАР № 5

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын булдыру, аларның урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирү турында» 12 нче апрель 2023 елның 6 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен пунктка туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын булдыру, аларның урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирү турында» 12 нче апрель 2023 елның 6 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урыны урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтына, районның җирле үзидарә органнары биналарындагы һәм авыл җирлекләрендәге мәгълүмат стендларына, әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка җиткерергә http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Мәллә-ТамакАвыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р.Насифуллина**